КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 октябрь г.Казань № 1217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 1 август, 919 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «(алга таба – Программа)» сүзләрен «(алга таба – дәүләт программасы)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 1 август, 919 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 1 август, 919 нчы карарына үзгәреш кертү турында» 2023 ел, 3 август, 941 нче.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин